ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТЕЛӘНЧЕ ТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

КАРАР

«03» апрель 2024 ел Телэнче Тамак авылы № __9__

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Телэнче Тамак авыл җирлеге составына керүче Хуҗи авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 09 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 09 ноябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Телэнче Тамак авыл җирлеге Хуҗи авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Телэнче Тамак авыл җирлеге Хуҗи авылында гражданнар җыенын билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Тукай муниципаль районы «Телэнче Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Телэнче Тамак авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Телэнче Тамак авыл җирлеге Советының 2019 елның 29 октябрендәге 47/2 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Телэнче Тамак авыл җирлеге составына керүче Хуҗи авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 09 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 09 ноябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Телэнче Тамак авыл җирлеге Хуҗи авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча 2024 елның 14 апрель 15.00 сәгатькә гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез үзгәрешләр кертергә ризамы:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Телэнче Тамак авыл җирлеге составына керүче Хуҗи авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 09 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына:

“-су белән тәэмин итү һәм су бүлү системаларын, суэтем башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Хуҗи авылының су күтәрү башнясы территориясен төзекләндерү (койма алу һәм урнаштыру)»;

2) түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 09 ноябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге Хуҗи авылында гражданнар җыены карарына:

“- су белән тәэмин итү һәм су бүлү системаларын, суэтем башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Хуҗи авылының су күтәрү башнясы территориясен төзекләндерү (койма алу һәм урнаштыру);”

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Теләнче Тамак авыл җирлеге, Хуҗи авылы, Үзәк ур., 34 йорт (мәчет бинасы яны)

4. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә махсус мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarsatan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тукай муниципаль районы
Теләнче Тамак авыл җирлеге Башлыгы Р.Ш. Назметдинов